КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 22 февраль г.Казань № 153

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 22 август, 407 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 22 август, 407 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 22 декабрь, 912 нче; 2010 ел, 19 июль, 577 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2012 ел, 7 февраль, 88 нче; 2012 ел, 12 октябрь, 847 нче; 2013 ел, 21 март, 196 нчы; 2013 ел, 11 июнь, 399 нчы; 2013 ел, 28 июнь, 446 нчы; 2013 ел, 29 август, 612 нче; 2014 ел, 17 гыйнвар, 21 нче; 2014 ел, 1 март, 133 нче; 2014 ел, 18 апрель, 255 нче; 2014 ел, 8 октябрь, 742 нче; 2015 ел, 22 гыйнвар, 28 нче; 2015 ел, 9 февраль, 72 нче; 2015 ел, 6 июль, 490 нчы; 2016 ел, 30 апрель, 269 нчы; 2016 ел, 9 июнь, 382 нче; 2016 ел, 12 октябрь, 737 нче; 2016 ел, 23 декабрь, 977 нче; 2017 ел, 6 март, 130 нчы; 2017 ел, 26 июнь, 439 нчы; 2017 ел, 7 декабрь, 950 нче; 2018 ел, 14 март, 151 нче; 2018 ел, 11 июнь, 461 нче; 2018 ел, 15 декабрь, 1139 нчы; 2019 ел, 15 июнь, 493 нче; 2019 ел, 2 июль, 525 нче; 2019 ел, 30 август, 735 нче; 2019 ел, 20 сентябрь, 859 нчы; 2020 ел, 28 гыйнвар, 31 нче; 2020 ел, 25 февраль, 141 нче; 2020 ел, 15 сентябрь, 830 нчы, 2020 ел, 10 ноябрь, 1006 нчы; 2021 ел, 15 июнь, 455 нче, 2021 ел, 19 июль, 587 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3 пунктта «предприятиеләр, учреждениеләр һәм башка» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Министрлык үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты указларына һәм боерыкларына, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Президенты указларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларына һәм боерыкларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.»;

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Министрлык үз компетенциясе чикләрендә түбәндәгеләр белән хезмәттәшлек итә:

3.2.1. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

гражданнар оборонасы өлкәсендә чаралар оештыру һәм үткәрү белән идарә итү (02.01.01*);

муниципальара һәм төбәк характерындагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү өлкәсендә идарә итү (02.01.02*);

Татарстан Республикасының янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү белән идарә итү (02.01.03*);

3.2.2. Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

энергияне һәм ресурсларны саклау белән идарә итү (01.14*);

сәнәгать белән идарә итү (03.01*);

3.2.3. Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

шәһәр төзелеше белән идарә итү (01.05*);

территориаль планлаштыру (01.05.01*);

объектларны төзү, капиталь ремонтлау һәм реконструкцияләү белән идарә итү (01.05.03*);

3.2.4. Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы белән дәүләт финанслары белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.02*);

3.2.5. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системаларын үстерү белән идарә итү (дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итүдән башка) функциясен гамәлгә ашырганда (01.15.02*);

3.2.6. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

социаль-икътисадый программалаштыру (01.01*);

инвестиция эшчәнлеге өлкәсендә җайга салу (01.09*);

инновацион эшчәнлекне үстерү белән идарә итү (01.11*);

Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү (01.15.01*);

3.2.7. Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы белән юстиция өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (02.03[*]);

3.2.8. Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты белән архив эше белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.17[*]);

3.2.9. Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы белән дәүләт-шәхси партнерлык һәм шәхси инвестицияләр өлкәсендә инвестицион эшчәнлекне үстерү белән идарә итү , инвестицион проектларны гамәлгә ашыруны комплексны тәэмин итү функцияләрен тормышка ашырганда(01.10[*]);

3.2.10. Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау буенча комитеты белән Татарстан Республикасы милкендәге мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану һәм аларны популярлаштыру функциясен башкарганда (04.03.03[*]).»;

3.3 пунктта:

3.3.27 пунктчада «Федераль закон» сүзләреннән соң «2002 елның 24 июлендәге 101-ФЗ номерлы» сүзләрен өстәргә;

3.3.32 пунктчаның өченче абзацында «Федераль закон» сүзләреннән соң «2002 елның 14 ноябрендәге 161-ФЗ номерлы» сүзләрен өстәргә;

3.3.50 пунктчаның икенче абзацында «Федераль закон» сүзләреннән соң «1995 елның 26 декабрендәге 208-ФЗ номерлы» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле $3.3.102^{5}$ пунктча өстәргә:

«$3.3.102^{5}$. Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең чиктәш субъектлары арасында чикләр билгеләү максатын куйган чараларны гамәлгә ашыруны оештыра, шул исәптән күрсәтелгән чикнең координаталар тасвирламасын килештерә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин